Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Никольский авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР

№ 2 01.02.2023

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 119 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 февраленнән Спас муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Никольский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Никольский авыл җирлеге битендә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Никольский авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Е.А.Синицин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «НИКОЛЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1637001491

2023 елның 1февралендәге 2 номерлы
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән ире, якын туганнары, башка туганнары, йә үлгәннәрне (һәлак булганнарны) җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү. | 2756,48 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү. | 1181,43 |
| 4. Кабер казу һәм күмү. | 3855,57 |
| Барлыгы | 7793,48 |

2022 елның 1февралендәге 2 номерлы
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Никольский авыл җирлеге башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Никольский авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән ире, якын туганнары, башка туганнары, йә үлгәннәрне (һәлак булганнарны) җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе.

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Гыйбадәт киемен кидерү | 443,04 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләр бирү һәм китерү. | 2313,44 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү. | 1181,43 |
| 5. Кабер казу һәм күмү. | 3855,57 |
| Барлыгы | 7793,48 |